СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**22.11.2018 ел** **№67**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 маендагы 47а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турындагы Нигезләмәдә.

1) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.1 Үзара салым акчаларын җыю тәртибе башкарма комитет карары белән билгеләнә».

2) 5.2-5.4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ